**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552) 3-44-22, факс (85552)3-44-14, E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

________ __________

Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 08.02.2021г. №07-10 Актаныш муниципаль районы Советы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.

2. Расларга:

Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Актаныш муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын (2 нче кушымта).

3. Актаныш муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлануын һәм биш ел тәшкил итүен билгеләргә.

4. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы административ комиссиясе составын раслау турында» 2006 елның 30 мартындагы ПР-40 номерлы карарын (04.06.2020 № ПР-112 үзг.белән) үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча:http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында түбәндәге адрес буенча:http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«____»__________2021ел
1 нче кушымта
№ПР-_______

Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе составы

| |
|---|
| Габдулхаев И.И. - административ комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Галимҗанова Р.Ф. - административ комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Советы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Мирзаянова А.Р. - административ комиссиянең җаваплы секретаре; |
| **Комиссия әгъзалары:** |
| Валиуллина А.Р. - Актаныш муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Әһлетдинова А.М. - Актаныш муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Хузеев М.А. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлек башлыгы, полиция подполковнигы (килешү буенча); |
| Арсланов М.Д. - күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Актаныш һәм Минзәлә муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән сорау алучысы (килешү буенча); |
| Усманов Р.М. - «Актаныш мәгълүмат-мөхәррият үзәге» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы директоры (килешү буенча); |
| Имамгалиева Ф.М. - Актаныш муниципаль районы юридик бүлегенең баш белгече (килешү буенча); |
| Бахтиева Л.Ф- массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Хафизова З.З.- Актаныш муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча) |
| Нурлыев Н.Г.- Актаныш районы ветераннар Советы Рәисе (килешү буенча) |
| Авыл башлыгы- (килешү буенча) |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«____»__________2021ел
2 нче кушымта
№ПР-_______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
административ комиссиясенең эш регламенты

Актаныш авылы
2021 ел

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
административ комиссиясенең эш регламенты

Әлеге регламент «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 281-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турындагы кодекс, Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодекс, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлеге административ комиссиясен төзү һәм оештыру һәм эшләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп эшләнгән.

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе (алга таба - административ комиссия) Актаныш муниципаль районы Советы тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 281 номерлы федераль законнар һәм «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә төзелгән.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карарлары, Актаныш муниципаль районы Уставы, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарлары һәм боерыклары, Актаныш муниципаль районы территориясен төзекләндерү өлкәсендә башка норматив-хокукый актлар һәм әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында (алга таба - ТР КоАП) каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы чикләрендә эш итә.

1.4. Административ комиссиянең бурычлары - административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба - РФ КоАП) һәм административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы (алга таба-ТР КоАП) нигезендә административ хокук бозу турындагы һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, чыгарылган карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү.

1.5. Актаныш муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча, үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан административ комиссиянең яңа әгъзасын билгеләргә тиеш.

1.8. Административ комиссиянең мөһере бар.

1.9. Административ комиссия төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты аша җирле бюджетка бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.10. Административ комиссия төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы гамәлгә ашыра.

## 2. АДМИНИСТРАТИВ КОМИССИЯ ЭШЕН ОЕШТЫРУ

2.1. Административ комиссия-рәис урынбасарыннан, җаваплы секретарьдан һәм административ комиссия әгъзаларыннан тора, аларны Актаныш муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе билгели.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм санлы составы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кимендә 5 әгъза күләмендә билгеләнә һәм так сан тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Даими штат нигезендә, административ комиссия составына, административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, шушы Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда административ комиссиядә эшлиләр.

2.5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча, административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими түләүле нигездә җирле бюджет акчалары хисабына башкара алалар. Административ комиссиянең агымдагы эше рәис тарафыннан расланган план буенча алып барыла.

2.6. Административ комиссия рәисе, урынбасары белән җаваплы секретарь арасында вазыйфаларны бүлә, аларның Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә функцияләрен билгели, бу тиешле боерык яисә административ комиссия буенча күрсәтмә белән беркетелә.

2.7. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра. Административ комиссиянең кадрлар сайлау эшен оештыру рәис тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.8. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Кабул итү тәртибе һәм вакыты административ комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә, алар тиешле күрсәтмә белән беркетелгән. Кабул итү вакытында кергән гаризалар һәм шикаятьләр законнарда билгеләнгән срокларда карала.

2.9. Административ хокук бозу турындагы эшне башкаруга, җаваплы секретарь административ комиссия утырышында аны карап тикшерүгә тиешле әзерлек үткәрә.

2.10. Административ комиссиядә билгеләнгән форма буенча статистик хисап алып барыла. Статистик белешмәләр квартал саен расланган форма буенча тапшырыла. Статистик хисаплылыкны дөрес һәм вакытында тапшыру өчен җаваплылык административ комиссия рәисенә йөкләнә, ә ул булмаганда - урынбасарга.

2.11. Административ хокук бозулар турындагы эшләр ике ел дәвамында административ комиссиядә саклана.

## 3. АДМИНИСТРАТИВ КОМИССИЯ УТЫРЫШЫНА ЧАКЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ

3.1. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру

буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләр комиссия рәисе, рәис урынбасары, җаваплы секретаре һәм әгъзалары, эштә катнашучы башка затлар һәм аларның вәкилләре составындагы административ комиссия утырышында карала.

3.2. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән очракта кабул ителә, ләкин аена кимендә бер тапкыр. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы белән уздырыла.

3.3. Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, ачык һәм хәбәрдар рәвештә алып барыла. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала. Административ комиссия утырышлары утырышлар залында законнар таләпләрен үтәп үткәрелә, ә утырышлар залы булмаганда эшләрне башка биналарда карау рөхсәт ителә.

3.4. Административ комиссия карары буенча аның утырышлары ябык булырга мөмкин. Аларда административ комиссия әгъзалары, хокук саклау органнары җитәкчеләре һәм махсус чакырылган затлар гына катнаша ала.

3.5. Административ комиссия утырышы аның составының кимендә өчтән ике өлеше булганда тулы хокуклы. Карар, административ хокук бозулар турындагы эш буенча утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.6. Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео- һәм фотога төшерү административ комиссия рәисе рөхсәте белән башкарыла.

3.7. Административ комиссия утырышын әзерләүне җаваплы секретарь башкара, ул карауга билгеләнгән эшләр исемлеген төзи, рәислек итүчегә эшне карау мөмкинлеге турында хәбәр итә, якларның килүен һәм вәкаләтләрен тикшерә, шулай ук өстәмә материаллар килүен тикшерә.

3.8. Билгеләнгән вакытта административ хокук бозу турындагы эшне тикшерү өчен рәислек итүче комиссия утырышын ачып җибәрә, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокук һәм бурычларны аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гариза, үтенечнамәләре бармы, утырыш белән җитәкчелек итә, эшнең барлык шартларын тулы һәм һәрьяклы ачыклауга ярдәм итә, утырышта тиешле тәртип тәэмин итә.

3.9. Беркетмәне карау рәислек итүче административ материалның шартлары турындагы докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.10. Әгәр комиссия утырышына каралучы административ эш буенча чакырылган як вәкилләре килсә, рәис, рәис урынбасары, әгъзалары аларга сораулар бирергә хокуклы.

3.11. Административ эш буенча докладтан соң комиссия беркетмә турында фикер алышуга күчә, анда комиссия әгъзалары гына катнаша. Административ комиссия карарларына административ комиссия рәисе һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан кул куела.

3.12. Административ комиссиянең һәр утырышында җаваплы секретарь тарафыннан башкарыла торган беркетмә алып бару мәҗбүри. Беркетмә административ комиссия рәисе һәм җаваплы секретарь тарафыннан административ комиссия утырышы тәмамланганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча әзерләнергә һәм имзаланырга тиеш.

3.13. Эшне кичектерү, тәнәфес игълан итү һәм эшне яңадан карау гамәлдәге закон таләпләрен үтәп башкарыла.

3.14. Эшне карау тәмамлангач, административ комиссия карар чыгару өчен тәнәфес игълан итә, бу хакта рәислек итүче утырыш залында игълан итә.

3.15. Административ комиссия карарларын бирү, аларны җибәрү административ комиссия әгъзалары тарафыннан башкарыла.

3.16. Комиссия утырышы барышында административ комиссия рәисе тарафыннан кабул ителгән күрсәтмәләрнең һәм карарларның үтәлешен контрольдә тоту җаваплы секретарь тарафыннан башкарыла.

## 4. АДМИНИСТРАТИВ КОМИССИЯ КАРАРЛАРЫ

4.1. Административ комиссия карары рәис тарафыннан игълан ителә һәм имзалана.

4.2. Бер үк вакытта утырышта катнашучы затлар һәм аларның вәкилләренә административ комиссия карарына шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

4.3. Карарның күчермәсе өч көн эчендә тапшырылырга яки аңа карата карар чыгарылган затка җибәрелергә тиеш.

4.4. Карарның күчермәсе расписка астында тапшырыла. Әгәр карарның күчермәсе җибәрелә икән, эштә тиешле язма ясала.

4.5. Административ комиссиянең законлы көченә кергән карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

4.6. Карарның үз вакытында бирелүен һәм карарларның күчермәләрен җибәрүне контрольдә тоту административ комиссиянең җаваплы секретаренә йөкләнә.

4.7. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр яисә протестлар законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ҖӘЗА САЛУ ТУРЫНДА КАРАРНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ

5.1. Административ хокук бозу турындагы эш буенча административ комиссия карары барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

5.2. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, законлы көченә кергәннән соң үтәлергә тиеш.

5.3. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан, административ штраф салу турында карар законлы көченә кергән көннән, алтмыш көннән дә соңга калмыйча яисә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 31.5 статьясында каралган кичектереп тору яисә кичектереп тору срогы чыккан көннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

5.4. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан банкка яки башка кредит оешмасына кертелә яки күчерелә.

5.5. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга шикаять, карарның күчермәсен тапшырганнан соң, ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин.

5.6. Административ штрафны түләү турында таныклаучы документ булмаганда, карар законлы көченә кергән көннән алтмыш көн узгач, административ комиссия федераль законнарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен суд приставына - башкаручыга тиешле материалларны җибәрә.

5.7. Штраф салу рәвешендәге административ җәза гаепле затларны рөхсәт ителгән җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгыннан азат итми.

## 6. АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАРНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ

6.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия эчке эшләр органнары, суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үз эшчәнлеген координацияли.

6.2. Административ комиссия, комиссия рәисе раслаган график нигезендә күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән Актаныш муниципаль районы җирлегендә дә.

6.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән профилактик эш оештыра.